ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацы; «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.А. Миронова шикаяте буенча**

Казан шәһәре 2017 елның 6 феврале

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Т.А. Миронова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Т.А. Миронова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (Казан шәһәр Думасының 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының (алга таба шулай ук — Устав) 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацы; «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3.3 пункты; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 54 пунктындагы 1 пунктчасы; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының (алга таба шулай ук — Регламент) 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Уставның 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү Казан шәһәр Думасы вәкаләтләренә керә дип каралган.

Тәртипнең 3.3 пункты нигезендә чыгымнарның максатчан билгеләнеше буенча Казан шәһәренең муниципаль юл фондының расланган бюджет ассигнованиеләре күләме бүленеше алдагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы 1 пунктчасы юл территорияләрен

карап тоту юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге машина юлларын төзекләндерүне үз эченә ала дип билгели.

Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге дәгъвалана торган нигезләмәләр Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләрен билгелиләр.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче яши торган Казан шәһәре, Академик Лаврентьев урамы адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортның ишегалдындагы юлның һәм тротуарларның асфальт түшәмәсе йорт кулланылышка тапшырылганнан бирле (1983 елдан) ремонтланмаган һәм хәзерге вакытта бик нык таушалган һәм тулысынча җимерек хәлдә. Ишегалды территориясе, машина үтә торган юл өлеше һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ремонтлауны сорап, әлеге йортта яшәүчеләр Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә, «“Уютный дом” идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә мөрәҗәгать иткән. Ләкин ишегалдындагы юл һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ремонтлау эшләре башкарылмаган.

Гражданка Т.А. Миронова фикеренчә, Тәртипнең 3.3 пункты, юл фондының бюджет ассигнованиеләрен бүлү вәкаләтен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына тапшырып, андый бүленешне башкарганда, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацыннан күренгәнчә, җирле администрация таянырга тиешле һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы дәрәҗәсендә билгеләнелергә тиешле бернинди дә критерийлар билгеләми. Башкасы, ул уйлаганча, әлеге фондтагы акчаларның ирекле бүленешенә һәм ремонтланырга тиешле юлларны һәм квартал эчендәге машина юлларын объектив булмаган сайлауга китерә, бу аның конституциячел хокукларын боза.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук билгеләгәнчә, Казан шәһәрен төзекләндерү

кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы юл территорияләрен карап тоту юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге машина юлларын төзекләндерүне үз эченә ала дип билгеләп, андый ремонт башкару тәртибен җайга салмый. Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге нигезләмәләр, аның фикеренчә, Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләренә юллар һәм тротуарлар ремонтлауны кертмиләр, бу Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре нигезләмәсенә квартал эчендәге машина юлларын ремонтлауны юл территорияләрен карап тотуга кертми торган аңлатма бирә. Шул ук вакытта, гражданка Т.А. Миронова күрсәткәнчә, элегрәк гамәлдә булган Регламентта юлларны җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләренә юллар һәм тротуарларга агымдагы ремонт ясау кертелгән булган.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган. Шуннан соң алар Казан шәһәр Думасының 2012 елның 7 июнендәге 4-14 номерлы карары белән расланган, 2013 елның 16 маендагы 17-22 номерлы, 2013 елның 25 декабрендәге 14-28 номерлы, 2014 елның 3 мартындагы 10-31 номерлы, 2014 елның 16 апрелендәге 15-32 номерлы карарлар белән үзгәрешләр 2012 елның 7 июнендәге 4-14 номерлы карар белән расланган Кагыйдәләргә кертелгән, ә 2014 елның 25 июлендәге 59-34 номерлы, 2014 елның 3 октябрендәге 27-36 номерлы, 2014 елның 29 октябрендәге 5-37 номерлы, 2015 елның 7 сентябрендәге 11-45 номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 19-2 номерлы карарлар белән үзгәрешләр Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләргә кертелгән. Шуңа бәйле рәвештә, аның фикеренчә, әлеге Кагыйдәләрнең раслануы белән аңлаешсызлык барлыкка килә. Мөрәҗәгать итүче санавынча, бу Казан шәһәр Думасы тарафыннан норматив хокукый

актны бастырып чыгару формасын үтәмәү булып тора, бу исә аның конституциячел хокукларын шулай ук боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Т.А. Миронова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (Казан шәһәр Думасының 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацын, «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пунктын, Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасын, «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләрен билгеле торган аерым нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан шулай ук Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен норматив хокукый актны бастырып чыгару формасы буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясындагы 5 пунктының бишенче абзацы нигезендә муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнә.

Әлеге закон күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатларында Уставның дәгъвалана торган нормасында Казан шәһәр Думасы — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы вәкаләтләренә шул исәптән Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү турында карар кабул итү буенча вәкаләт кертелгән.

Шулай итеп, Уставның 28 статьясындагы 1 өлешенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган кырык беренче абзацында аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең басылып чыгу формасы буенча конституциячел булмаулары турындагы мөрәҗәгать итүченең дәлилләренә килгәндә, шикаять әлеге өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан шулай ук карауга алына алмый дип билгеләп үтәргә кирәк. «“Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре турында” Казан шәһәр Думасы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Казан шәһәр Думасының 2015 елның 28 октябрендәге 19-2 номерлы карары белән гражданка Т.А. Миронова күрсәткән Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен үзгәртә торган норматив хокукый актлар ул Татарстан Республикасы Конституция судына

мөрәҗәгать иткәнгә кадәр үз көчен югалткан дип танылган, ә Кагыйдәләр исә яңа редакциядә бәян ителгән.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлешенең мәгънәсе буенча Татарстан Республикасы Конституция суды конституциячел суд эшләрен башкарганда гамәлдәге норматив хокукый актларның конституциячеллеген тикшерә. Шикаять итүче Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү алдыннан юкка чыгарылган яки үз көчен югалткан актларның конституциячеллеген тикшерү мөмкин түгел (Татарстан Республикасы Конституция судының 2010 елның 27 февралендәге 3-О номерлы билгеләмәсе).

Димәк, гражданка Т.А. Миронованың шикаяте Кагыйдәләрнең конституциячеллеген аларның басылып чыгу формасы буенча тикшерү өлешендә карала алмый.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы (дүртенче өлеш) һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр буенча Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты, шулай ук җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә. Димәк, Тәртипнең 3.3 пункты, Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы 1 пунктчасы һәм Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсенә тикшерелергә мөмкин.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең бозылуына карата шикаять белән Татарстан Республикасы

законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән шул билгеләнгән: Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса. Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүченең шикаятенә кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләре дәгъвалана торган нигезләмәләрнең мөрәҗәгать итүченең конкрет эшен хәл иткәндә кулланылуын раслый торган итеп каралырга мөмкин.

Шуның белән гражданка Т.А. Миронова шикаяте Тәртипнең 3.3 пунктының, Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы 1 пунктчасының һәм Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керә, тиешле мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында билгеләнгән шикаять бирү таләпләренә туры килә, һәм анда Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга алудан баш тарту өчен нинди дә булса нигезләр юк.

4. Шикаятьтә күрсәтелгәнчә, мөрәҗәгать итүче пенсионер һәм авыр матди хәлдә булганга күрә, ул үзен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итүне сорый.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 42 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы

Конституция судына мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә алына. Россия Федерациясе Салым кодексының 333.23 статьясындагы 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектларының конституция (устав) судлары, түләүченең матди мөмкинлекләреннән чыгып, аны күрсәтелгән судлар карый торган эшләр буенча дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә яки аның күләмен киметергә, шулай ук әлеге Кодексның 333.41 статьясында каралган тәртиптә аны түләүне кичектерергә (бүлгәләп түләтергә) хокуклы.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданка Т.А. Миронованың үзен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү турындагы үтенечен канәгатьләндерергә мөмкин дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 42 статьясына, 45 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 51 статьясындагы беренче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Гражданка Т.А. Миронова шикаятен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (Казан шәһәр Думасының 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацының һәм басылып чыгу формасы буенча Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алудан баш тартырга, чөнки әлеге өлештә ул «Татарстан

Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми.

2. «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.А. Миронова шикаятен карауга кабул итәргә.

3. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

4. Гражданка Т.А. Миронова шикаяте, гражданнар Л.И. Новоселова һәм П.П. Гуров шикаятьләре бер үк предметка кагылганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясы нигезендә әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерергә.

5. Гражданка Т.А. Миронованың үтенечен аны дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү турындагы өлешендә канәгатьләндерергә.

6. Кабул ителгән карар турында якларга — гражданка Т.А. Мироновага, Казан шәһәр Думасына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына хәбәр итәргә.

7. Әлеге эш буенча докладчы судья итеп Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Р.Г. Сәхиеваны билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге эшне карап тикшерү көнен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында эшләрне тыңлау чираты тәртибендә билгеләргә.

9. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 6-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**